ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында” Татарстан Республикасы Законына һәм “Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында” Татарстан Республикасы Законының 28 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 11 мартында
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында” 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 1 – 2; 2011, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2014, № 1 – 2, № 5; 2015, № 10 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяның 2 өлешендә:
а) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“2) юридик затның исеме яисә индивидуаль эшкуарның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта);”;
б) 3 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

2) 8 статьяның 1 өлешендә “инновация-технология үзәкләрен,” сүзләреннән соң “индустрия паркларын,” сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 10 статьяның 2 өлешендә “Федераль законның 4 статьясында билгеләнгән шартларга һәм” сүзләрен төшереп калдырырга;

4) 13 статьяның 4 өлешендәге 1 пунктында “читләштерелгән мөлкәт” сүзләрен “читләштерелергә мөмкин булган мөлкәт” сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

“Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында” 2012 елның 22 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 28 статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2) эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында Россия Федерациясе законнары нигезендә медицина эшчәнлеген лицензияләү;”.

**3 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге статья белән үз көчләренә керүнең башка вакытлары билгеләнгән нигезләмәләреннән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 3 пункты 2016 елның 1 августыннан үз көченә керә.

3. 2016 елның 1 августына кадәр юридик затларны һәм индивидуаль эшкуарларны кече һәм урта эшкуарлык субъектларына кертү һәм аларны кече һәм урта эшкуарлык субъектлары категорияләренә кертү өчен “Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында” 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясында (“Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2015 елның 29 декабрендәге 408-ФЗ номерлы Федераль закон үз көченә кергән көнгә кадәр гамәлдә булган редакциясендә) билгеләнгән шартлар кулланыла.

4. Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына кертү өчен “Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында” 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясында (“Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2015 елның 29 декабрендәге 408-ФЗ номерлы Федераль закон үз көченә кергән көнгә кадәр гамәлдә булган редакциясендә) билгеләнгән шартларга җавап бирүче юридик затлар һәм индивидуаль эшкуарлар аларга кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә юнәлдерелгән чараларны үз эченә алган Татарстан Республикасы дәүләт программалары (ярдәмче программалары) һәм муниципаль программалар (ярдәмче программалар) нигезендә 2016 елның 1 августына кадәр күрсәтелгән ярдәмгә хокукны 2016 елның 31 декабренә кадәр саклап калалар.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2016 елның 26 марты
№ 20-ТРЗ